

Мордовия Республикасы Дәvләт Собраниесынын республикада региональ һәм федераль максатчан программаларны тормышка ашыру буенча законнарга vзгәрешләр кертv буенча сессиясе vтте.
Сессиядә бvгенге Мордовия бюджеты һәм 2018 ел планнарына vзгәрешләр керттеләр, транспорт һәм башка тор (региональ налог һәм штраф, процентлар) налоглар жыю турында сойләделәр. 2018нче елга Мордовия пенсионерынын яшәv минимумын дәлилләделәр, Республика Мордовия Счётная палатасына, Дәvләт Собраниясенә депутлар сайлау буенча, халыкара, хокvмәтара килешvләргә карата һәм башка олкәләрдә Законга vзгәрешләр кертv каралды. Шулай ук Дәvләт Собраниесе федераль законнарга vзгәрешләр кертv проекты, Мордовия жирле мировой судьяларын кую һәм башка сорауларга тукталып хәл ителде чираттагы утырышта.      Башта финанс турында. Искәртеп vтик, шушындый очрашулар - парламен-тарийларнын федераль бюджеттан республика икътисадына акча жәлеп итv буенча традицион эш формасы. Региональ казнаны vстерv очен федераль бюджеттан 320 миллион сум акча кертелде. 300 миллион сум Саранск башкалабыз тирә-ягы юлларын ясау очен, 10 миллион – радиациягә дучар булганнарга социаль яклау чыгымнарына, калган 10 миллион сум мәгариф олкәсе мәсьәләләрен хәл итv очен һәм инвалид балаларга дарулар очен каралган. Тагы, вице-премьер – Мордовиянен финанс министры Алексей Симонов тәгъдиме белән, жирле парламентариләребез бюджет эчендәге кайбер эчке  финанс агымнарын vзгәрттеләр. Шулай, казнадан 260 миллион сум хокvмәт учрежденияләрен тәэмин итvгә юнәлтелде; шунын 190 миллион сум – зарплатага, 144 - Мордовиянен хокvмәт бурычын капларга юнәлтелергә дигән карар чыгардылар. Әйтеп китәргә кирәк, финанс ел агымында Мордовия хокvмәт бурычы 148,9% кимегән.
Алдынгы vсеш алган Рузаевка шәһәренен vсешенә налог льготалары да каралды. Ун елга шәһәр 10% кадәр льгота алыр. Сессиядә катнашкан Мордовия Главасы Владимир Волков:  «...образование в Рузаевке территории опережающего социально-экономического развития имеет огромное значение для всей республики. Создание ТОСЭР не только поможет стабилизировать обстановку в железнодорожной столице Мордовии, но и активизирует создание агломерации Рузаевка-Саранск. …В ближайшие три-четыре года сюда планируется привлечь более 10 млрд. инвестиций, построить крупные инновационные предприятия и подтянуть малый бизнес. Это в значительной степени скажется на качестве жизни наших людей, что очень важно…»,- дип ассызыклады.
Сессия утырышында транспорт налогларын (коче 150 «ат» автомобильлеләр очен),

инвалид балалар тәрбияләнгән гаиләләргә киметергә дигән карар булды. Бу чикләv региональ бюджетка 4,2 миллион сумга тошәр. Шул ук вакытта, башка автохужаларга транспорт налогын vстерергә карар кылдылар. Налоглар 15 елдан карт һәм кочләре 100 «ат» булганнарга кагылмас, ничек бар - 15 сум һәрбер мощность берәмлеге очен, шулай калыр. Ә 200 - 250 «ат»лылары очен - 75, ә 250дән артыгы - 100 сум булыр. Ә унбиш елдан яшьлеләренә бер «ат»ка 2,7 сумнан 20 сумга кадәр артыр. Тагы налог кvләме мотоцикл һәм мотороллер, автобус, катер, моторлы коймә, снегоход, яхта һәм самолетларга, йок машиналарына арта. Шул рәвештә Мордовия бюджетына остәмә 88,3 миллион сум транспорт налогы керергә тиеш.
Сессиядә пенсионерларга да хормәт кvрсәттеләр: 2018нче елда бу категория кешеләр очен яшәv минимумын 8194 сум иттереп билгеләделәр һәм ул пенсиягә остәмәләр рәвешендә артыр.
Сессия азагына якынлашканда, Мордовиянен Верховный суд Рәисе Сергей Штанов мировой судья вазыйфасына соискательләрне тәгъдим итте. Әлегә бу вазыйфа ачык калган; Владимир Макейкин сайлауларны vтмәгән.
Барлыгы унжиде сорау каралды Мордовия Республикасы Дәvләт Собраниесенен унжиденче сессиядә.

**Наилә Насырова**